**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**БОЕРЫК**
28.06.2019

Казан шәһәре

**БОЕРЫК**
№ 78

Татарстан Республикасының туристлык буенча дәүләт комитетында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабреннән 2124-1 номерлы Рәсәй Федерациясе канунының 48 маддәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының туристлык буенча дәүләт комитетында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Рәис С. Е. Иванов

Татарстан Республикасының
туристлык буенча дәүләт
комитетының
28.06.2019 нән 78 номерлы
боерыгы тарафыннан
расланган

# Татарстан Республикасының туристлык буенча дәүләт комитетында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабреннән 2124-1 номерлы Рәсәй Федерациясе канунының 48 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасының туристлык буенча дәүләт комитетында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен (алга таба - аккредитация, Дәүләт комитеты) регламентлый.

1.2. Аккредитация срогы чикләнмәгән. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге буенча аккредитация конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәк булган срокка, яки аккредитацияләнгән журналистны аның вакытлыча булмавы очрагында (вакытлы аккредитация) алыштыру өчен башкарылырга мөмкин.

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитациягә милек формасына һәм гамәлгә куючыларның составына, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чараларына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен аны Рәсәй Федерациясенең Чит ил эшләре министрлыгында аккредитацияләүне раслау зарур.

## III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитациягә гариза Дәүләт комитетына Дәүләт комитеты тарафыннан күрсәтелгән гаризаны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы белән тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазифасы, эш һәм кәрәзле телефоннар, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турындагы таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын Рәсәй Федерациясенең Чит ил эшләре министрлыгында аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә аккредитацияне

раслаучы документларның күчермәләре куела.

Вакытлы аккредитациягә гаризада шулай ук редакция биреме һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, ә аккредитацияләнгән журналистны аның вакытлыча булмавы сәбәпле алыштырган очракта - аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм алмаштыручы журналистны аккредитацияләү вакыты күрсәтелә.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация (аккредитацияләүдән баш тарту) турында карар Дәүләт комитеты рәисе (аның вазифаларын башкаручы зат) тарафыннан гариза килгән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар Дәүләт комитеты рәисенең тиешле боерыгы басылып чыккан көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә фактны, датасын һәм вакытын редакция тарафыннан расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда булган очракта (реклама тарату, эротик басмалар) аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.6. Гаризаны карау, дәүләт комитеты рәисенең аккредитация (аккредитацияләүдән баш тарту) турында боерыгы проектын әзерләү, шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә мәгълүмат бирү әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Дәүләт комитетында массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар киләсе хокукларга ия:

чарада катнашу;

Дәүләт комитеты карамагында булган чара турында рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистика, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

басылу өчен каралган мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышу;

Рәсәй Федерациясе кануннарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар киләселәргә бурычлы:

массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, чараның регламентын үтәргә һәм аның барышына тыкшынмаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

Дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән публикацияләрдә (эфирда эшләгәндә) пресс-релизларны, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материалларны кулланганда мәгълүмат чыганагына таянырга;

үз һөнәри эшчәнлегеңне гамәлгә ашырганда Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.